ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

29 01 2021 г. № 13

Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2014 елның 26 мартындагы 45 номерлы карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының көтелгән үтәү йомгаклары һәм 2021 елга Татарстан Республикасы финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегиясе беркетмәсенең 24 пунктын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының «Түбән Кама шәһәрендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2015 елның 1 декабрендәге 480 номерлы карары нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2014 елның 26 мартындагы 45 номерлы карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» баганасаның 2.6. пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында мәгълүмат.».

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Р. Салаватов